СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

# КАРАР

**« 02 » апрель 2021 ел** **№ 1**

**Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге 123 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Шушмабаш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларь турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 96 номерлы (18.12.2020ел, №17 үзгәрешләр белән) номерлы карары белән расланган “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халыкның авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашуга хокукын тәэмин итү максатыннан карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Шушмабаш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2021 елның 03 маена билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Шушмабаш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 15.00 сәгатьтә ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1в йорты адресы буенча уздырырга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш

кагыйдәләренә карата тәкъдим ителгән үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәрен, кисәтүләрен һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризаларын язмача рәвештә 2021 ел, 03 май көненең 15.00 сәгатенә кадәр ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1Б йорты адресы адресы буенча җибәрәләр, дип билгеләргә. Телефон 8(84366) 93-1-24.

4. Әлеге карарны һәм Шушмабаш авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карары проектын Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районы рәсми сайтында «Район җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН1609012678